ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«25.» 11 2019 ел** **№ 261**

Балтач муниципаль районында Халыкара инвалидлар көненә
әзерлек һәм аны үткәрү турында

Инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү буенча уздырыла торган чараларның эшен оештыруны камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. 2019 елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр районда Халыкара инвалидлар көненә багышланган Инвалидлар декадасын әзерләргә һәм үткәрергә.

2. Расларга:

- Балтач муниципаль районында Халыкара инвалидлар көне кысаларында чаралар әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясе составын (1 нче кушымта)
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планын (2 нче кушымта).

3. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләренә, министерстволарның һәм ведомстволарның Балтач муниципаль районындагы территориаль органнары башлыкларына районда инвалидлар декадасын әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын үтәү өчен кирәкле чаралар күрергә;
- районның шәһәр җирлеге һәм авыл җирлекләре башлыкларына инвалидларның район чараларында катнашуын оештырырга;
- оешмаларга, предприятиеләргә, шәхси эшмәкәрләргә авыр тормыш хәленә эләккән инвалидларга иганәчелек ярдәме күрсәтүдә актив катнашырга;
- социаль яклау бүлеге башлыгы А.Ф. Гатиятуллинага башкарылган эш турында йомгаклау мәгълүматын әзерләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Хәйретдиновка йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин

Балтач муниципаль район
башлыгының
2019 елның «25» ноябрендәге
261 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Балтач муниципаль районында Халыкара инвалидлар көне кысаларында чаралар әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Сабирҗанов Н.Н. | Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Гайнетдинов И.Ф. | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Нургалиев Р.К. | Балтач район башкарма комитетының оештыру-гомуми бүлеге җитәкчесе, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| Ильясов Р.М. | Балтач район башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Нотфуллин Г.Р. | Балтач районы буенча РФ Пенсия Фонды идарәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гатиятуллина А.Ф. | Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Шагаева А.Ю. | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе (килешү буенча); |
| Дәүлиев Г.Д. | ДАССУ «Балтач үзәк район хастаханәсе» баш табибы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р.Р. | Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сәләхетдинова Р.Н. | Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе вазифаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Абдуллин Р.Г. | Балтач муниципаль районы ветераннар советы рәисе (килешү буенча); |
| Сөләйманов Г.И. | «Таттехмедфарм» Дәүләт унитар предприятиесенең 27 нче Үзәк район даруханәсе мөдире (килешү буенча); |
| Фәрзиев Р.Ф. | Балтач муниципаль районының инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча); |
| Зәкиев В.М. | «Татмедиа» ААҖ филиалының «Хезмәт» газетасы редакциясенең баш мөхәррире, «Изгелек» Балтач хәйрия фонды директоры (килешү буенча); |
| Маннапова Г.С. | МУ ТРК «Кайтаваз» директоры (килешү буенча). |

Балтач муниципаль район башлыгының
2019 елның «25» нояберендәге
261 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында Халыкара инвалидлар көненә багышланган чаралар планы

| № | Муниципаль район | Датасы | Чара | Үткәрү урыны (адресы) | Көтелә торган кешеләр саны | Вазыйфасы, ФИАИ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Балтач | 02.12.2019 | Район башлыгы Р.Р. Нотфуллинның инвалидлар белән очрашуы;<br>Очрашу кичәсе: "Күлләр яктырсын, йөрәкләр җылынсын өчен." | Мәдәният үзәге штп. Балтач, Ленин урамы, 52 нче йорт. | 320 | мәдәният бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Сәләхетдинова |
| 2 | Балтач | 03.12.2019 | Дартс һәм бочча буенча ярышлар | “Факел” яшүсмерләр клубы штп. Балтач, Ленин урамы, 154 нче йорт. | 45 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Р.Р. Заһидуллин |
| 3 | Балтач | 03.12.2019 | "ГТО барлык кеше өчен" ("ГТО для всех") | “Факел” яшүсмерләр клубы штп. Балтач, Ленин урамы, 154 нче йорт. | 35 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Р.Р. Заһидуллин |
| 4 | Балтач | 04.12.2019 | Пневматик винтовкадан ату ярышы | “Факел” яшүсмерләр клубы штп. Балтач, Ленин урамы, 154 нче йорт. | 25 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Р.Р. Заһидуллин |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Балтач | 06.12.2019 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен мастер-класс "Оста куллар" ("Умелые ручки") | “Факел” яшүсмерләр клубы штп. Балтач, Ленин урамы, 154 нче йорт. | 45 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Р.Р. Заһидуллин |
| 6 | Балтач | 06.12.2019 | Район халкы өчен "Дуслар җыелган жирдә" мөмкинлекләре чикләнгән затлар концерты | Салавыч авылы мәдәният йорты Иске Салавыч авылы, Татарстан урамы, 2 нче йорт. | 350 | район инвалидлар җәмгыяте мәдәният бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Сәләхетдинова белән берлектә |
| 7 | Балтач | 12.12.2019 | Социаль яклау бүлеге, пенсия фонды, социаль иминиятләштерү фонды, үзәк район хастаханәсе вәкилләре һәм инвалидлар җәмгыяте рәисе белән "Түгәрәк өстәл" | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге "Наз" социаль-тернәкләндерү бүлеге, Чепья авылы, Школьная урамы, 14/1 нче йорт | 60 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 8 | Балтач | 25.12.2019 | "Исәнме, Яңа ел!" ("Здравствуй, Новый год!") Яңа ел утренниклары, мәктәп чаралары.<br>Өйдә белем алучы укучыларны котлау | Районның мәгариф оешмалары | 2500 | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе А.Ю. Шагаева Районның мәгариф оешмалары җитәкчеләре, сыйныф җитәкчеләре |
| 9 | Балтач | 27.12.2019 | "Дуслар әйләнәсендә" ("В кругу друзей") район яңа ел тамашасын үткәрү | Мәдәният үзәге штп. Балтач, Ленин урамы, 52 нче йорт. | 168 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина мәдәният бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Сәләхетдинова белән берлектә |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Балтач | 27.12.2019 | "2019 ел хәйриячесе" ("Благотворитель 2019 года") конкурсына йомгак ясау | Район башкарма комитетының конференц-залы штп. Балтач, Ленин урамы, 45 нче йорт. | 350 | Балтач муниципаль район башлыгы Р.Р. Нотфуллин |
| 11 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Мөмкинлекләре чикләнгән затларга кирәкле ярдәм күрсәтү, аларны кызыксындырган сораулар консультацияләр уздыру максатларында "Кайнар линия" телефоннары эше | Социаль яклау бүлеге, штп. Балтач, Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | - | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 12 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Күңел җылысын бүләк ит" ("Подари тепло души") Инвалидларга шефлык ярдәме күрсәтү, ялгызларның һәм инвалидның өйләренә бару , өйдә белем алучы балаларга хәлдән килгәнчә ярдәм итү, концерт оештыру | Яшәү урыны буенча | 2500 | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе А.Ю. Шагаева Районның мәгариф оешмалары җитәкчеләре, сыйныф җитәкчеләре |
| 13 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | «Дөнья яхшылыкка йөз тота» ("Мир держится на доброте")<br>Класс сәгатьләре, әңгәмәләр, түгәрәк өстәлләр, акцияләр, хәйрия ярминкәләре | Районның мәгариф оешмалары | 3600 | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе А.Ю. Шагаева Районның мәгариф оешмалары җитәкчеләре, сыйныф җитәкчеләре |
| 14 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | «Яхшылык җир буйлап бара...»<br>Рәсем, кулдан ясалган әйберләр конкурсын үткәрү.<br>Инвалидлар декадасына багышланган китаплар һәм фотосурәтләр күргәзмәләрен оештыру | Районның мәгариф оешмалары | 1500 | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе А.Ю. Шагаева Районның мәгариф оешмалары җитәкчеләре, сыйныф җитәкчеләре |
| 15 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Бергә күңеллерәк"("Вместе веселее") клубы кысаларында дәресләр үткәрү | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге "Наз"<br>штп. Балтач, | 28 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | | |
| 16 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Кыш бабайга хат" ("ПисьмоДеду Морозу") хәйрия акциясе. Социаль хезмәт күрсәтүдәге балаларга хәйрия ярдәме күрсәтү | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге "Наз" штп. Балтач, Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | 10 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 17 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Әни көне" ("Мамин день") проектын гамәлгә ашыру | социаль участокларда | 12 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 18 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Битараф булмыйк" ("Не будем равнодушными") Инвалидлык төркеме булган районның танылган кешеләре белән очрашулар | Районның мәгариф оешмалары | 1500 | Балтач район башкарма комитетының МКУ «Мәгариф идарәсе» җитәкчесе А.Ю. Шагаева Районның мәгариф оешмалары җитәкчеләре, сыйныф җитәкчеләре |
| 19 | Балтач | даими рәвештә | Инвалид балаларның ата-аналарын консультацияләү (мөмкинлекләре чикләнгән балалары булган ата-аналарга педагогик ярдәм) | "Балтач районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ психология-педагогика хезмәте | 200 | "Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ Психологик-педагогик хезмәт җитәкчесе Ф.Р.Мөхәммәтгалиева |
| 20 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Яңа ел кар бабае" ("Новогодний снеговик") чыршы уенчыгы эшләнмәләре конкурсы | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге "Наз" штп. Балтач, Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | 168 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру максатында саф һавада сәламәтләндерү дәресләре | Район буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы II һәм III группа инвалидларының яшәү зоналары буенча | 112 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 22 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | "Безнең кулларның җылысы" ("Тепло наших рук") социаль хезмәт күрсәтү бүлегенең кул астындагылар арасында конкурс | Район буенча | 112 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 23 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Авыл китапханәләрендә тематик кичәләр һәм китап күргәзмәләре | Авыл клублары | 360 | мәдәният бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Сәләхетдинова |
| 24 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Инвалидлар хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча юридик консультация | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге "Наз", штп. Балтач, Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | 28 | Балтач муниципаль районындагы ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Наз" халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәге", Т.С. Зәкиева Инвалидлар җәмгыяте һәм "Наз" халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексы үзәге" юристы белән берлектә Балтач шәһәр җирлеге, юрисконсульт Р.Т. Гильванов |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 25 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Социаль ярдәмгә мохтаҗ балалы гаиләләрне төрле технологияләр кулланып социаль ярдәмнең нәтиҗәле практикаларын үстерү чаралары Комплексын гамәлгә ашыру: хезмәт реабилитациясе; "Парикмахер эше" ("Парикмахерское дело") һәм Тегүчелек эше" ("Швейное дело") | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге "Наз", штп. Балтач, Х.Такташ урамы, 3а номерлы йорт. | 10 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 26 | Балтач | 02.12.-10.12.2019 | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне компьютер белеменә өйрәтү | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге "Наз" социаль-тернәкләндерү бүлеге, Чепья авылы, Школьная урамы, 14/1 нче йорт | 56 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 27 | Балтач | 02.12.2019 | "Наз хәбәрләр" газетасының махсус номерын чыгару | район буенча | 1 000 | социаль яклау бүлеге җитәкчесе А.Ф. Гатиятуллина |
| 28 | Балтач | даими рәвештә | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша эшкә урнаштыруга ярдәм итү мәсьәләләре буенча инвалидларга мәгълүмат бирү | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге штп. Балтач, Совет урамы, 16 нчы йорт | - | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры А.Р. Нургалиев "Хезмәт" газетасының баш мөхәррире В.М. Зәкиев |
| 29 | Балтач | даими рәвештә | Инвалидларга һөнәри ориентация буенча хезмәт күрсәтү | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге штп. Балтач, Совет урамы, 16 нчы йорт | - | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры А.Р. Нургалиев |